**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче**
**Яңа Мусабай авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# КАРАР

26 ноябрь, 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Яңа Мусабай авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1 000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү (Майская ур., Лесная ур.).
- Урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **234** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **120** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **120** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Яңа Мусабай авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2022 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Яңа Мусабай авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1 000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү (Майская ур., Лесная ур.).

- Урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары сатып алу.

3. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Яңа Мусабай авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Яңа Мусабай авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгы Ф.Г.Ихсанов